| СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның «09» декабре Өтәшкә ав. № 171

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеш нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча вәкаләтләренең бер өлеше тапшырылсын.

2. Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Башкарма комитеты Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны Өтәшкә авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына ел саен бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына гамәлгә ашырыла.

4. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү турында» 2024 елның 1 апрелендәге 145 номерлы карарның үз көчен югалтуы танылсын.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорты (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорты (СДК бинасы).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Өтәшкә авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **А. А. Клопов**

СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1620001214
ОГРН 1021606753486